Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

2020 елның 10 ноябре

№ 4

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мамашир авыл җирлегенең Мәмәшир авылында гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының 1 нче этабын 2020 елның 24 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта билгеләргә. Мамашир авылы, Яшьләр ур., 29Б йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында гражданнар җыенын үткәрергә.

2.2020 елның 25 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә. Мамашир авылы, Яшьләр ур., 29Б йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында гражданнар җыенын үткәрергә.

3. 2020 елның 25 ноябрендә 19 сәгать 00 минутта Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын билгеләргә. Мәмәшир авылы, Октябрь урамы, 48а нче йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасында гражданнар җыены үткәрергә.

4.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: "2021 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан), 90 яшькә җиткән һәм аннан да өлкәнрәк, 4 баласы булган һәм аннан да күбрәк балалары булган, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалардан тыш, 2021 елда һәр бәлигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?:

- урамнарга вак таш түшәлгән юлларны ремонтлау , Мәмәшир авылы урам-юл челтәрен карап тоту, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.

- тирән насослар сатып алу һәм урнаштыру , Мамашир авылын су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау , проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Мәмәшир авылы чишмәләрен ремонтлау һәм карап тоту, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру.

- янгын гидрантларын комплектлау өчен сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру ;

- Мәмәшир авылында урамнарны яктыртуны җайга салу өчен урам яктырткычлары һәм махсус җиһазлар сатып алу .

- торак пункттан керү юлында (чыгу юлында) видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру ;

“Эйе” « КАРШЫ"»

5.Халык җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) хәл итәргә кирәк.

6. Халык җыенын Мәмәшир авыл җирлеге башкарма комитеты оештыра.

7. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгән көннән 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы и. г. Әхмәтҗанов

ОГРН 1021607753012
ИНН 1623001702